**Республика Татарстан**
**Альметьевское сельское поселение Сармановского муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районы**
**Әлмәт авыл җирлеге**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Әлмәт авылы **КАРАР**

14 март 2019 ел № 72

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы "Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Әлмәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә 2018 елның 18 ноябрендәге 180 номерлы җирле референдумда кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру максатларында Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты карар чыгарды.

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчасы җыю тәртибен (1 нче кушымта) расларга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында " (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Әлмәт авыл җирлеге башкама
комитеты җитәкчесе Д.Ә.Газизов

Сарман муниципаль районы Әлмәт
авыл җирлеге башкарма комитетының
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге тэртип Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү 18 яшькә җиткән һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан, 1 группа инвалидлардан, ялгыз өлкән кешеләрдән, көндезге бүлектә белем алучы студентлар тыш Һәм аларның саны авыл җирлегендә яшәүчеләрнең гомуми саныннан 30 проценттан артмаска тиеш, 2019 нчы елның 31 мартына кадәр, җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуына һәм тавыш биргәндә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә түләнә.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (белдерү) бланкы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында халыкка хәбәр итү юлы белән, шулай ук почта элемтәсе аша тапшыру яки җибәрү юлы белән гражданнар игътибарына җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (белдерүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерү реквизитлары, тулы яисә киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы (2 нче кушымта) күрсәтелә.

5. Гражданнарның үзара салым акчалары Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык хезмәте идарәсенең лицевой счетына (Сарман муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы) күчерелә.

6. Гражданнар тарафыннан түләү физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясау һәм почта аша күчерүгә хокуклы оешмалар аша, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша (сылтама буенча) башкарыла https://uslugi.tatarstan.ru/.

7. Түләү квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслау булып торалар.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары закон тпрафыннан билгеләнгән тәртиптә түләтерелә.

Сарман муниципаль районы Әлмәт
авыл җирлеге башкарма комитетының
карарына 1 нче кушымта

Әлмәт авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләү кертү турында
БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ№_____

Түләүченең Ф.И.Ә.И
_______________________________________________________________________________

Адресы: ______________________________________________________________

Нигезләмә ____________________________________________________________

Сезгә _________________________ кадәрле вакыт эчендә__________________________

чараны гамәлгә ашыру буенча ___________ сум күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләүне түбәндәге реквизитларга күчерергә кирәк:

Кабул итүче як банкы БИК ____________________________________

Кабул итеп алучы Сч. № ____________________________________________

ИНН _____________________________________________

КПП _____________________________________________

КБК ________________ ОКАТО ___________________

Түләүнең билгеләнеше
_______________________________________________________________________________

Җитәкче ___________________ ___________________________________________

М.У. (имза) (тулысынча язылыш)

------------------ **кисеп алу сызыгы** --------------

Әлмәт авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнә торган түләүне _______________ сум күләмендә түләү турында №______ белдерү кәгазе

Түләүченең Ф.И.А.И.
____________________________________________________________

Адресы:______________________________________________________________
_______________________________________________________________________________

Кабул ителде «__» ________________ 20__ ел. __________________________________

(түләүченең имзасы/фамилиясе)

*Искәрмә. Белдерү кәгазе түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта, түләү кәгазе өлеше(отрывной корешок) тутырыла һәм Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитетында кала*